**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 елның 5 нче июне** **№106**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендә кабул ителгән 62 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетынын 2010 елның 22 апрелендәге "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлек башкарма комитетларының баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт шартларын оештыру һәм аларның шартлары турында» гы 345 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 62 номерлы карарына» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарнын 1 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5 нче бүлек өстәргә:

**5. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары хезмәте өчен түләү шартлары (муниципаль хезмәткәрләр вазифаларына кертелгән вазыйфалардан тыш)**

1. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерына хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск, айлык премияләр һәм эш нәтиҗәләре буенча премияләр биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән тора.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлек башкарма комитеты |
|---|---|
| | 3,5 мен кешегэ кадар |
| Баш хисапчы | 15 700 сум |
| Икътисадчы | 13 391 сум |

4. Хезмәткәрләргә билгеләнә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә, процентларда |
|---|---|
| 1 дән 5 елга кадәр | 5 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 7 |
| 10 нан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан күп | 15 |

2) эшнен катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләме елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә;

Әгәр хисапчыларга календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча исэплэнелэ һәм декабрьдә эшләнелгән вакытка пропорциональ, рәвештә түләнелә, эштән азат ителгән очракта-эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Ел саен түләнә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә кадар эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

5) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә премияләр, вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә айлык премия, (премия күләме хезмәткәр

эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми)

5. Бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t)$$

ФОТ - еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$- аена вазыйфаи окладларны түләү өчен акча суммасы;
$0{,}3 * O_d$- тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;
р- еллык премия фонды (вазыйфаи окладның бер процентыннан чыгып билгеләнә торган));
n- штат саны;
k-12 ай;
т-хезмәт өчен түләү буенча түләүләр исәпләү."

2. Әлеге карар 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы рәисе Х.Х. Ибәтов